ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 483-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.Н. Шәфигуллин, Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 483-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2180-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.Н. Шәфигуллин,
Р.Р. Гайзатуллин,
М.Һ. Галиев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Законы

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле $7^2$ пункт өстәргә:

«$7^2$) газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләрнең газ кулланучыларны газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган объектларына хосусыйлаштырганда йөкләнгән эксплуатация йөкләмәләренең үтәлешен тикшереп тору тәртибен билгели;»;

2) 8 статьяның 2 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа ундүртенче абзац өстәргә:

«Газ бүлү челтәрләрен, газ куллану челтәрләрен һәм мондый челтәрләрнең газ кулланучыларны газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган объектларын хосусыйлаштырган очракта, аларга йөкләнгән эксплуатация йөкләмәләре хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарга мөһим шарт буларак кертелергә тиеш.»;

б) ундүртенче һәм унбишенче абзацларны тиешенчә унбишенче һәм уналтынчы абзацлар дип санарга;

3) 10 статьяда:

а) исемдә «Акционер җәмгыять акцияләрен, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлешләрен, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын» сүзләрен «Дәүләт мөлкәтен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә:

беренче абзацта «(алга таба – мәдәни мирас объектлары)» сүзләреннән соң «, газ бүлү челтәрләрен, газ куллану челтәрләрен һәм мондый челтәрләр объектларын» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «объектларына» сүзеннән соң «, газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләр объектларына» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында" 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә әлеге Федераль закон нигезендә торышы канәгатьләнмәслек дип танылган мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен үткәрү;»;

түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясы нигезендә башка шартлар.»;

сигезенче һәм тугызынчы абзацларны тиешенчә сигезенче һәм тугызынчы абзацлар дип санарга;

4) 15 статьяның 1 өлешендә «күрсәтелгән объектлардан» сүзләрен «мондый объектлардан» сүзләренә алмаштырырга, «тәэмин итүгә таләпләр» сүзләреннән соң «, мондый объектлар һәм аларның территорияләрендә тышкы реклама урнаштыруга таләпләр, шулай ук мәдәни мирас объекты турында мәгълүматы булган язулар һәм билгеләр урнаштыруга таләпләр» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 345-ФЗ номерлы Федераль закон белән (ул рәсми басылып чыккан көненнән соң туксан көн узгач – 2023 елның 23 октябрендә) үз көченә керә) акционер җәмгыять акцияләрен, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлешләрне, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрнең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын сатканда үткәрелә торган конкурс шартларына, шул исәптән, газ бүлү, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләр объектларына карата ремонт һәм башка эшләр үткәрү шартларын кертү мөмкинлеге билгеләнгән. Газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләрнең газ кулланучыларны газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган объектларына карата эксплуатация йөкләмәләренең үтәлешен тикшереп тору тәртибе дәүләт хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 июлендәге 370-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – 178-ФЗ номерлы Федераль закон) әлеге конкурсны уздыру шартларын һәм мәдәни мирас объектлары реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын хосусыйлаштыру үзенчәлекләрен җайга сала торган үзгәрешләр кертелде, алар 2023 елның 4 августыннан үз көченә керде. Кертелгән үзгәрешләр буенча конкурс шартларында, 178-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 21 пунктында санап үтелгән шартлар белән бергә, әлеге Федераль законның 29 статьясы нигезендә башка шартлар да кертелергә мөмкин булуы ачыкланды.

Мәдәни мирас объектларын хосусыйлаштыру шартларына аларның мондый объектларда һәм бу объектлар территорияләрендә тышкы реклама урнаштыру таләпләренә, шулай ук мәдәни мирас объекты турында мәгълүмат булган язмалар һәм билгеләр урнаштыру таләпләренә туры килергә тиешлеге хакында йөкләмәләр өстәлде.

Федераль законнардагы югарыда күрсәтелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә закон проекты белән «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының бүтән законнарын кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләрнең газ кулланучыларны газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган объектларына хосусыйлаштырганда йөкләнгән эксплуатация йөкләмәләренең үтәлешен тикшереп тору тәртибен билгеләү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнар таләп итми.